ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 390 от «08» 11 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 сентябрендәге 520 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 статьясының 2 пункты, 2 подпункты, «Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге ТРЗ-108 Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге ТРЗ-109 Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 сентябрендәге «Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау хакында» 520 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенең 2 пунктының 6 пунктчасындагы «бакчачылык» сүзеннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче О.Н. Павлов

0000011460